**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 15 июль № 515

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Куркыныч объектларга, халыкның тереклеген тәэмин итүче системалар объектларына һәм халыкның тупланып тору объектларына Татарстан Республикасы документларының территориаль иминият фондын үстерү турында» 2006 ел, 17 апрель, 173 нче карары белән расланган Куркыныч объектларга, халыкның тереклеген тәэмин итү системасы объектларына һәм Татарстан Республикасында халык күп җыела торган объектларга Татарстан Республикасы документларының территориаль иминият фондын төзү өчен документларның электрон күчермәләрен тапшыру тәртибенә һәм Куркыныч объектларга, халыкның тереклеген тәэмин итү системасы объектларына һәм Татарстан Республикасында халык күп җыела торган объектларга Татарстан Республикасы документларының электрон күчермәләрен алу яки территориаль иминият фондын төзү өчен кәгазьдә документлар бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетын КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Куркыныч объектларга, халыкның тереклеген тәэмин итүче системалар объектларына һәм

халыкның тупланып тору объектларына Татарстан Республикасы документларының территориаль иминият фондын үстерү турында» 2006 ел, 17 апрель, 173 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 8 май, 298 нче, 2010 ел, 12 ноябрь, 897 нче, 2015 ел, 9 февраль, 73 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган Куркыныч объектларга, халыкның тереклеген тәэмин итү системасы объектларына һәм Татарстан Республикасында халык күп җыела торган объектларга Татарстан Республикасы документларының территориаль иминият фондын төзү өчен документларның электрон күчермәләрен тапшыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1 пунктка «мөһер белән расланган» сүзләреннән соң «(Россия Федерациясе законнарында мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда)» сүзләрен өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Куркыныч объектларга, халыкның тереклеген тәэмин итүче системалар объектларына һәм халыкның тупланып тору объектларына Татарстан Республикасы документларының территориаль иминият фондын үстерү турында» 2006 ел, 17 апрель, 173 нче карары белән расланган Куркыныч объектларга, халыкның тереклеген тәэмин итү системасы объектларына һәм Татарстан Республикасында халык күп җыела торган объектларга Татарстан Республикасы документларының электрон күчермәләрен алу яки территориаль иминият фондын төзү өчен кәгазьдә документлар бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1 пунктка «мөһер белән расланган» сүзләреннән соң «(Россия Федерациясе законнарында мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда)» сүзләрен өстәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\515.doc